| | |
|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО ПРОМЫШЛЕННОСТИ И ТОРГОВЛИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СӘНӘГАТЬ ҺӘМ СӘҮДӘ МИНИСТРЛЫГЫ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

__20.11.2023__ Казан ш. №__220-ОД__

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына гражданнардан коррупциячел юнәлешле фактлар буенча килгән мөрәҗәгатьләр белән эшләү тәртибе турында

«Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 21 статьясы нигезендә
б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына гражданнардан коррупциячел юнәлешле фактлар буенча килгән мөрәҗәгатьләр белән эшләү тәртибен (кушымтада бирелә) расларга.
2. Билгеләргә:

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына гражданнардан коррупциячел юнәлешле фактлар буенча килгән мөрәҗәгатьләрне карау Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының кадрлар бүлеге һәм юридик бүлеге катнашында Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгында коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы зат тарафыннан гамәлгә ашырыла;

коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләүче вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә хезмәт мәгълүматларының һәм конфиденциаль рәвештәге мәгълүматларның сакланышы өчен җаваплы була.

3. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары –
министр О.В. Коробченко

Татарстан Республикасы
Сәнәгать һәм сәүдә
министрлыгының 2023 елның
«_20__»___11_______ 220-ОД
номерлы боерыгы белән
расланды

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына гражданнардан коррупциячел юнәлешле фактлар буенча килгән мөрәҗәгатьләр белән эшләү тәртибе

1. Әлеге Тәртип «Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 21 статьясын үтәү йөзеннән эшләнде һәм Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгында (алга таба – Министрлык) коррупция һәм ришвәтчелек фактлары, гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен чикләү, гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозу турында белешмәләрне үз эченә алган коррупция юнәлешендәге фактлар буенча, шулай ук Министрлыкта Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре (алга таба – хезмәткәрләр) тарафыннан, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булып тормаган вазыйфаларны били торган һәм Министрлыкта эшчәнлекне техник яктан тәэмин итү һәм хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыра торган эшчеләр (алга таба – эшчеләр) тарафыннан кылынган, хезмәт хәленнән явызларча файдалану билгеләрен үз эченә алган башка гамәлләр турында гражданнардан алынган мөрәҗәгатьләрне (алга таба – мөрәҗәгать) карау үзенчәлекләрен билгели. Бүтән затларга карата шундый ук фактлар турында белешмәләрне үз эченә алган мөрәҗәгатьләр «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы федераль законның 8 статьясының 3 өлеше нигезендә мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрне хәл итү алар компетенциясенә карый торган тиешле органга яки тиешле вазыйфаи затка җибәрелергә тиеш.

2. Мөрәҗәгать «Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы федераль законда билгеләнгән тәртиптә һәм вакытларда теркәлә һәм карала.

Мөрәҗәгатьтә хокукка каршы килә торган гамәлнең әзерләнүе, кылынуы яки кылынганлыгы турында, шулай ук аны әзерләүче, кылучы яки кылган зат турында белешмәләр булса, мөрәҗәгать компетенцияләренә ярашлы рәвештә хокук саклау органнарына җибәрелергә тиеш.

3. Кадрлар бүлеге тарафыннан мөрәҗәгать теркәлгән көннән алып ике эш көненнән дә артмаган вакытта «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә хезмәткәргә карата хезмәт тикшерүен үткәрү инициативасы куела (хезмәткәрдән язмача аңлатмалар таләп ителә).

4. Хезмәт тикшерүен үткәргән комиссия бәяләмәсе нигезендә коррупция чагылышлары билгеләре булуы турында мөрәҗәгатьтә бәян ителгән фактлар расланган очракта, министр (аның вазыйфаларын башкаручы зат) әлеге бәяләмәне алган көннән алып өч эш көне эчендә Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясенә күрсәтмә кертә. Хезмәткәргә карата тиешле фактлар расланган очракта, аның язма аңлатмаларын анализлаудан чыгып, аңа карата Россия Федерациясе норматив хокукый актларында каралган җаваплылык чараларын куллану мәсьәләсе хәл ителә.

Хезмәт тикшерүе, шулай ук хезмәткәрнең язмача аңлатмаларын анализлау нәтиҗәләре буенча әзерләнә торган, кылына торган яисә кылынган законга каршы гамәлләр турында, шулай ук аны әзерләүче, эшләүче яки кылган кеше турында билгеле булган очракта, әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән вакыт эчендә тиешле мәгълүмат, компетенциясе нигезендә, хокук саклау органнарына җибәрелергә тиеш.

5. Мөрәҗәгать җибәргән гражданинга җавап әзерләү Министрлыкта коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы зат тарафыннан башкарыла.

Министрлыкның кадрлар бүлеге, шулай ук юридик бүлеге Татарстан Республикасының ведомствоара электрон документлар әйләнеше бердәм системасы аша Министрлыкта коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы затка гражданинга җавап җибәрү вакыты тәмамланганчы 15 көннән дә соңга калмыйча мөрәҗәгать буенча язма тәкъдимнәр җибәрәләр.

6. Әгәр мөрәҗәгатьтә җаваплы затка карата коррупциячел юнәлешле фактлар турында мәгълүмат булса, җаваплы зат аны карауда катнашмый. Мондый мөрәҗәгатьне карау кадрлар бүлеге, шулай ук Министрлыкның юридик бүлеге тарафыннан башкарыла.